ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

16.09.2024
1394

КАРАР

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» 2023 елның 12 октябрендәге 1518 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының 2023 елның 12 октябрендәге 1518 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 5 пунктындагы 6 пунктчасының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

системасына, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчалар, шулай ук Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (нотариаль гамәлләр кылган, куркыныч, авыр һәм эре габаритлы йөкләрне ташучы транспорт чаралары автомобиль юллары буйлап хәрәкәткә рөхсәт биргән, реклама конструкциясе урнаштыруга рөхсәт биргән өчен, административ штрафлар өчен дәүләт пошлинасы) һәм Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы тарафыннан (аренда түләүләре, җир кишәрлекләрен һәм мөлкәтне сатудан керемнәр, административ штрафлар) һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре бюджеты керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган түләү өчен кирәкле мәгълүматны, тиешле сумма исәпләнә торган көннән соңга калмыйча тапшыру;».

1.2. Тәртипнең 4 пунктындагы 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчалар, шулай ук Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (нотариаль гамәлләр кылган, куркыныч, авыр һәм эре габаритлы йөкләрне ташучы транспорт чаралары автомобиль юллары буйлап хәрәкәткә рөхсәт биргән, реклама конструкциясе урнаштыруга рөхсәт биргән өчен, административ штрафлар өчен дәүләт пошлинасы) һәм Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы тарафыннан (аренда түләүләре, җир кишәрлекләрен һәм мөлкәтне сатудан керемнәр, административ штрафлар) һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре бюджеты керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган түләү өчен кирәкле мәгълүматны, тиешле сумма исәпләнә торган көннән дә соңга калмыйча тапшыралар;».

1.3. Тәртипнең 4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 13 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 1394 от 16.09.2024
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 16.09.2024 14:47

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>17.09.2024 - 10:43 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН